КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 февраль г.Казань № 109

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 734 нче; 2017 ел, 28 август, 608 нче һәм 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче һәм 2018 ел, 11 июнь, 455 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

7 – 8 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, 284 нче карары белән расланган форма буенча бизнес-план;

8) объектны урнаштыруны, проектны тормышка ашыруны финанслау мөмкинлеген раслаучы документлар:

«Намуссыз төзүчеләрнең гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән күпфатирлы йортларны өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча чаралар күрсәтү өчен индивидуаль торак йортлар һәм (яки) күпфатирлы йортлар төзү» критериясе буенча проектны гамәлгә ашыру очрагында проект инициаторы – юридик затның расланган үз акчалары күләме бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең кимендә 5 проценты күләмендә билгеләнә;

сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы идарә компаниясеннән үтенечнамә кергән очракта, үз акчалары булу идарәче компаниянең үз акчалары яисә сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы резидентларының үз акчалары белән раслана. Расланган үз акчалары күләме идарәче компаниянең бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең 30 процентыннан яисә сәнәгать (индустриаль) паркының, сәнәгать мәйданчыгының һәр резиденты бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең 30 проценттан да ким булмаска тиеш;

проектны гамәлгә ашыруның, объектны урнаштыруның калган очракларында, проекты инициаторы булган юридик затның расланган үз акчалары күләме бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты күләмендә билгеләнә, әмма соралган җир кишәрлегенең агымдагы кадастр бәясеннән артмаска тиеш.

Проект инициаторы – юридик затның үз акчалары күләме Россия Федерациясе Финанслар министрлыгының «Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы формалары турында» 2010 ел,02 июль, 66н номерлы боерыгы белән расланган 0710001 формасы буенча бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының «III. Капитал һәм резервлар» бүлегенең нәтиҗәсе белән раслана.

Агымдагы ел чорында юридик зат югарыда күрсәтелгән формада, бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тәкъдим итәргә хокуклы;»;

түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) «Намуссыз төзүчеләрнең гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән күпфатирлы йортларны өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча чаралар күрсәтү өчен индивидуаль торак йортлар һәм (яки) күпфатирлы йортлар төзү» критериясе буенча проектны гамәлгә ашырган очракта проект инициаторы – юридик зат тарафыннан үтенечнамә составында шулай ук түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

территориясендә проблемалы объект урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы, үтенечнамәне биргән юридик зат (инвестор) һәм объект балансында булган юридик зат арасында төзелеп килүче намуссыз төзүче тарафыннан төзелеп бетмәгән (төзелеп килүче) күпфатирлы йортны (күпфатирлы йортларны) (алга таба-проблемалы объект) төзүне гражданнар акасын җәлеп итеп тәмамлау турында килешү (төзелешкә инвестицияләр кертү турында килешү);

территориясендә проблемалы объект урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы үткәргән проблемалы объект төзелешен тәмамлау чыгымнарын бәяләү;

бәяләүче тарафыннан «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килә торган җир кишәрлеге бәясен бәяләү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин